ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11 октябрь 2011 ел № 6661

Башкарма комитетның 2014 елның 18 ноябрендәге 7047 номерлы карары белән расланган «2015-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2014 елның 18 ноябрендәге 7047 номерлы карары (Башкарма комитетның 2014 елның 8 декабрендәге 7609 номерлы, 2016 елның 30 мартындагы 1423 номерлы, 2016 елның 20 маендагы 2539 номерлы, 2018 елның 12 мартындагы 1243 номерлы, 2018 елның 6 сентябрендәге 4995 номерлы, 2019 елның 29 мартындагы 1613 номерлы, 2019 елның 16 сентябрендәге 4704 номерлы, 2020 елның 13 августындагы 3930 номерлы, 2021 елны 20 февралендәге 1209 номерлы, 2021 елның 6 августындагы 5222 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган «2015-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасына, 4 бүлекнең 1 нче «Коррупциягә каршы эшчәнлекне норматив-хокукый һәм оештыру ягыннан тәэмин итү» пунктын кушымтада каралганча бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2021 елның 11 октябрендәге
6661 номерлы карарына
кушымта

## 4 бүлек. Программа чараларының исемлеге һәм кыскача тасвирламасы

| № т/б | Чараларның исеме | Башкаручы | Башкару срогы | Көтелгән нәтиҗә | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау | Еллар буенча чыгымнар суммасы, мең сум | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
| 1. Коррупциягә каршы эшчәнлекне норматив-хокукый һәм оештыру ягыннан тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Федераль законнар нигезендә һәм республикада коррупциягә каршы гамәлдәге нормаларны куллану практикасын гомумиләштерү нигезендә, коррупциягә каршы тору турында муниципаль хокукый актлар эшләү һәм күрсәтелгән муниципаль хокукый | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Коррупциягә каршы тору өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу нәтиҗәлелеген арттыру, әлеге өлкәдә хокукый җитешсезлекләрне һәм каршылыкларны бетерү | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | актларга үзгәрешләр кертү | | | | | | | | | | | | | | |
| 2 | Хокукый актлар нигезендә коррупцион хокук бозуларны кисәтү буенча функцияләр бирелгән җаваплы затларны билгеләү | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Коррупциягә каршы тору эшендә персональ җаваплылыкны, оешканлыкны һәм һөнәри осталыкны арттыру | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |
| 3 | Муниципаль хезмәт турындагы, коррупциягә каршы тору турындагы законнар таләпләрен үтәп, муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан хезмәткәрләрнең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерүләр үткәрү | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тулы һәм дөрес мәгълүмат бирүгә ирешү | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт турындагы законнарда каралган хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлешенә тикшерүләр үткәрү | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль хезмәткәрләрнең Этика кодексында һәм хезмәт тәртибендә билгеләнгән, муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы билгеләнгән стандартын үтәүгә һәм хезмәт тәртибенә ирешү | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |
| 5 | Законнарда билгеләнгән тәртиптә, муниципаль хезмәткәрдә мәнфәгатьләр конфликты булу яки барлыкка килү мөмкинлеге турында яллаучының вәкиленә керә торган мәгълүматны тикшерү | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибен кимчелексез үтәвенә ирешү | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |
| 6 | Яллаучының (эш бирүченең) вәкиле тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, муниципаль хезмәткәрне коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында аларга мөрәҗәгать иткәндә, муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләр конфликты | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | фактлары турында мәгълүматларны тикшерү | | | барлыкка килгән очракта халкының ачыклыгына ирешү | | | | | | | | | | | |
| 7 | Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең чикләүләрне, тыюларны үтәү буенча һәм коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны, шул исәптән бүләкләр алуга кагылышлы чикләүләрне үтәү буенча оештыру, аңлату һәм башка чаралар үткәрү | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында чикләүләр һәм тыюлар, таләпләр үтәлүгә ирешү | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |
| 8 | Җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи дәрәҗәләренә бәйле рәвештә яки аларның хезмәт вазыйфаларын үтәвенә бәйле рәвештә, аларга | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында чикләүләр һәм тыюлар, таләпләр үтәлүгә ирешү | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бүләкләр бирүгә карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру буенча чаралар үткәрү | | | | | | | | | | | | | | |
| 9 | Муниципаль вазыйфалар, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларга, коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен, шул исәптән коммерцияле сатып алу, ришвәт алу һәм бирү, ришвәт алуда арадашчылык өчен коммерцияле сатып алу яки ришвәт суммасына тапкырланган күләмдәге штрафлар рәвешендә җәза билгеләү турында, ышаныч югалуга бәйле рәвештә эштән азат итү турында, коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге затлар тарафыннан | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында чикләүләр һәм тыюлар, таләпләр үтәлүгә ирешү | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тапшырыла торган белешмәләрне тикшерү тәртибе турында җиткерү | | | | | | | | | | | | | | |
| 10 | Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюлар, чикләүләр һәм таләпләр үтәлмәгән һәр очракта, законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын куллануны контрольдә тотуны тәэмин итү | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Коррупциягә каршы тору инструментларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру ягыннан камилләштерү | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | - | - | - | - | - |
| 11 | Коррупциягә каршы тору буенча комиссиянең нәтиҗәле эшләвен, шул исәптән аның эшчәнлегенә иҗтимагый советлар вәкилләрен һәм башка граждан җәмгыяте институтларын җәлеп итү юлы белән тәэмин итү | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Коррупциягә каршы тору буенча тагын да нәтиҗәлерәк эшләү өчен шартлар тудыру, коррупциягә каршы эшчәнлеккә җәмәгатьчелек вәкилләренең киң даирәсен җәлеп итү | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |
| 12 | Коррупциягә каршы комиссия тарафыннан якларның берсе булып муниципаль вазыйфалар, муниципаль хезмәт | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү | 2015-2024 | Коррупциягә каршы тору буенча комиссия эшчәнлеген активлаштыру һәм муниципаль хезмәт | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | вазыйфаларын биләүче затлар торган мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү очракларын ачыклау буенча эшнең торышы һәм аны камилләштерү чаралары турындагы мәсьәләне карап тикшерү | буенча), Башкарма комитет | | системасында коррупцион куркынычларны киметү | | | | | | | | | | | |
| 13 | Җирле үзидарә органнары тарафыннан үз функцияләрен гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган коррупцион куркынычларны бәяләүне системалы (елга бер тапкыр) үткәрүне оештыру һәм коррупция куркынычы белән бәйле муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коррупцион хокук бозуларны булдырмау өчен оештыру-хокукый шартлар булдыру | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |
| 14 | Муниципаль оешмаларда, комиссияләр составына җирле үзидарәнең вәкиллекле | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү | 2015-2024 | Коррупцион хокук бозуларга карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | аппаратлары һәм (яки) башкарма органнары вәкилләрен җәлеп итеп, коррупциягә каршы тору буенча комиссияләр төзү | буенча), Башкарма комитет | | | | | | | | | | | | | |
| 15 | Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы оешмаларында: «Шәһәр төзелешен үстерү хезмәте» МУП, «Электротранспорт» МУП, «Автомобиль юллары предприятиесе» МУП коррупцияне кисәтү буенча эш оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе | 2015-2024 | Коррупциягә карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | - | - | - | - | - |
| 16 | Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия эшен оештыруны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015-2024 елларга Татарстан | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында чикләүләр һәм тыюлар, таләпләр үтәлүгә ирешү | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы Карары белән билгеләнгән таләпләргә туры китерү | | | | | | | | | | | | | | |
| 17 | Муниципаль хезмәт турында законнар һәм коррупциягә каршы тору турында законнар нигезендә җирле үзидарә органнары сайтларында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат урнаштыру | Башкарма комитет | 2015-2024 | Җирле үзидарә органнары эшчәнлегендә ачыклыкны һәм файдалану мөмкинлеген тәэмин итү, муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәрен һәм мөлкәтен иҗтимагый контрольдә тоту өчен шартлар тудыру | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |
| 18 | Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны, муниципаль хезмәткәрләрне, шул исәптән вазыйфаи бурычларына коррупциягә каршы | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), | 2015-2024 | Коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы затларның һөнәри осталыгын арттыру | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | торуда катнашу кергән затларны һөнәри әзерләүне һәм яңадан әзерләүне оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет | | | | | | | | | | | | | |
| 19 | Коррупция күренешләренә карата мөнәсәбәтне билгеләү өчен, муниципаль хезмәткә керешүче гражданнар, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр арасында ирекле тест (сораштыру) үткәрү | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә кандидатларның мораль-психологик һәм эшлекле сыйфатларын объектив бәяләү | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |
| 20 | Эш алганда (вазыйфага билгеләнгәндә) гражданнарның гавами хакимият органнары белән үзара эшчәнлегендә коррупцион куркынычларны киметү максатларында, муниципаль хезмәт өлкәсендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары таләпләрен тайпылышсыз үтәүне | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупцион хокук бозуларга карата тискәре мөнәсәбәтен формалаштыру | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тәэмин итү буенча чаралар күрү | | | | | | | | | | | | | | |
| 21 | Коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре җитәкчеләре белән киңәшмәләр үткәрү | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Коррупцион хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә эшнең гомуми принципларын һәм методларын эшләү, уңай тәҗрибә белән уртаклашу | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |
| 22 | Уставтагы бурычы булып коррупциягә каршы торуда катнашу торган иҗтимагый оешмаларны һәм башка гражданлык җәмгыяте институтларын җәлеп итеп, җирле үзидарә органнарында коррупциягә каршы тискәре мөнәсәбәт формалаштыру буенча эшне активлаштыру | Шәһәр Советы (килешү буенча), Контроль-хисап палатасы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Коррупциягә каршы тору инструментларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру ягыннан камилләштерү | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |
| 23 | Бюджет акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту | Башкарма комитетның финанс идарәсе, Контроль-хисап палатасы | 2015-2024 | Бюджет акчаларын куллану нәтиҗәлелеген арттыру | Чаралар оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | (килешү буенча) | | | | | | | | | | | | | |
| 24 | Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмауга һәм җайга салуга кагылышлы, коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары таләпләре үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыру, билгеләнгән таләпләрне үтәмәүчеләрне дисциплинар җаваплылыкка тарту | Шәһәр Советы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы стандартларын үтәүгә ирешү | Чара оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |
| 25 | Муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның шәхси делоларын алып баруга кагылышлы өлешендә кадрлар эшенең нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән мәнфәгатьләр | Шәһәр Советы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның анкетасындагы мәгълүматларның дөреслеген арттыру | Чара оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | конфликтын ачыклау максатларында, күрсәтелгән вазыйфаларга билгеләнгәндә һәм мондый хезмәткә керешкәндә бирелә торган анкетадагы мәгълүматларны актуальләштерүне контрольдә тоту буенча чаралар күрү | | | | | | | | | | | | | | |
| 26 | Коррупциягә каршы тору өлкәсендә белем бирү программалары буенча норматив хокукый актларда билгеләнгән вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфаларны биләү өчен, муниципаль хезмәткә беренче тапкыр керешүче муниципаль хезмәткәрләрне махсус укыту | Шәһәр Советы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Коррупциягә каршы сәясәт өлкәсендә белемнәрне күтәрү | Чара оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |
| 27 | Вазыйфаи бурычларына коррупциягә каршы торуда катнашу кергән муниципаль хезмәткәрләрнең | Шәһәр Советы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы затларның һөнәри осталыгын арттыру | Чара оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | квалификацияләрен ел саен махсус күтәрү | | | | | | | | | | | | | | |
| 28 | Кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары тарафыннан коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләре һәм аларны бозган өчен җәзаның котылгысызлыгы турында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның, муниципаль берәмлектә эш итүче иҗтимагый совет әгъзаларының хәбәрдарлыгын арттыру буенча чаралар күрү | Шәһәр Советы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында чикләүләр һәм тыюлар, таләпләр үтәлүгә ирешү | Чара оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |
| 29 | Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу мәсьәләләрен көйләүче нормалар | Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль учреждениеләр (предприятиеләр) тарафыннан коррупциягә | Чара оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | өлешендә ведомство буйсынуындагы оешмалар уставларына, ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре белән хезмәт шартнамәләренә үзгәрешләр кертү | | | каршы сәясәтне үтәүгә ирешү | | | | | | | | | | | |
| 30 | Ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре тарафыннан ведомство буйсынуындагы оешмалар уставларының һәм хезмәт шартнамәләренең мәнфәгатьләр конфликтын булдырмауга һәм җайга салуга кагылышлы таләпләре үтәлешен контрольдә тоту, шул исәптән әлеге таләпләр үтәлмәгән очракта, мәнфәгатьләр конфликтын | Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль учреждениеләр (предприятиеләр) тарафыннан коррупциягә каршы сәясәтне үтәүгә ирешү | Чара оештыру характерына ия | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | булдырмау һәм җайга салу турында таләпләр таралуга мөнәсәбәтле затларны җаваплылыкка тартып, аны булдырмау һәм/яки җайга салу буенча чаралар күрү | | | | | | | | | | | | | | |
| 30.1 | Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затларның коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашуына мониторинг үткәрү | Шәһәр Советы (килешү буенча), Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль учреждениеләр (предприятиеләр) тарафыннан коррупциягә каршы сәясәтне үтәүгә ирешү | Чара оештыру характерына ия | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 30.2 | «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясында каралган чараларны күрү, шул исәптән Башкарма комитет карамагындагы оешмаларның мәнфәгатьләр конфликтын ачыклау, булдырмау һәм җайга салу буенча бурыч | Башкарма комитет | 2015-2024 | Муниципаль учреждениеләр (предприятиеләр) тарафыннан коррупциягә каршы сәясәтне үтәүгә ирешү | Чара оештыру характерына ия | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | | | | |
| 30.3 | Вазыйфаи бурычларына муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларны үткәрүдә катнашу кергән хезмәткәрләрнең, муниципаль хезмәткәрләрнең ел саен коррупциягә каршы тору өлкәсендә квалификациясен күтәрүне тәэмин итү | Башкарма комитет | 2015-2024 | Коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы затларның һөнәри осталыгын арттыру | Чара оештыру характерына ия | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева